КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 20 гыйнвар г.Казань № 27

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләре һәм махсус хәрби операциядә катнашу аркасында һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 ел, 20 октябрь, 1122 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 14 ноябрь, 1213 нче; 2023 ел, 20 март, 291 нче; 2024 ел, 9 апрель, 243 нче; 2024 ел, 20 май, 343 нче; 2024 ел, 18 июнь, 435 нче; 2024 ел, 6 август, 624 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 23 статьясындагы 2 өлеше нигезендә яраклы эш эзләү максатлары белән теркәлгән гаилә әгъзасын, аңа яраклы эш бирү мөмкинлеге булмаган очракта, эшсез дип тану турында карар кабул итү халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан әлеге зат яраклы эш эзләүдә булышлык итү буенча дәүләт ярдәме чаралары күрсәтү турында гариза биргән көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин